| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

25.06.2026 Казан ш. 1623-р

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 19.11.2024 № 3710-р боерыгы белән расланган 2025 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 7 пунктына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^1$ статьясына, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 26 июлендәге № 66-ЗРТ Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.86 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 карары белән расланган Россия Федерациясе Салым

кодексының 378$^{2}$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару Тәртибенең 6 пунктына, салым салу максатларында биналар (каралты, корылма) һәм йортларның фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссиянең 2026 елның 25 июнендәге № 14 карарына, Татарстан Республикасы Арбитраж Судының № А65-35951/2025 эш буенча 2026 елның 12 февралендәге карарына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “2025 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” 19.11.2024 № 3710-р боерыгы белән расланган 2025 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә (алга таба – Исемлек) (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.12.2024 № 4250-р, 22.01.2025 № 80-р, 30.01.2025 № 241-р, 03.02.2025 № 311-р, 16.05.2025 № 1648-р, 03.06.2025 № 1875-р, 24.06.2025 № 2078-р, 17.07.2025 № 2442-р, 25.07.2025 № 2579-р, 20.08.2025 № 2903-р, 25.09.2025 № 3419-р, 01.11.2025 № 4020-р, 14.11.2025 № 4184-р, 02.12.2025 № 4711-р, 10.12.2025 № 5019-р, 19.01.2026 № 35-р, 03.02.2026 № 172-р, 03.03.2026 № 429-р, 01.05.2026 № 1104-р, 09.06.2026 № 1480-р боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 49, 891, 1101 пунктларны төшереп калдырып үзгәрешләр кертергә.

2. Үзгәрешләр исәпкә алынган Исемлекне электрон формада тиешле тәртиптә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Исемлекне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында https://mzio.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлләре 2025 елның 1 гыйнварыннан соң булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешене контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.Ә.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**